2025 елда Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Ямаши авылы җирлеге Ямаши авылында гражданнарның үзара салымын кертү турында

## ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

21 ноябрь 2024 ел № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Ямаши авыл җирлегенең Ямаши авылында гражданнар җыены карар кабул итте:

1. 2025 елда Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Ямаши авыл җирлеге Ямаши авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән 500 сум күләмендә үзара салым кертергә, мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылганнардан, вакытлы хезмәт узу өчен яисә Россия Федерациясе Оборона министрлыгы белән контракт төзегән гражданнардан тыш.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә: су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау (су белән тәэмин итү челтәрләрен алмаштыру)?”.

3. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга Ямаши авылы, Совет урамы, 4 йорт территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә Әлмәт муниципаль районы сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Ямаши авыл җирлеге башлыгы А.А. Андревкина